| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ**

28.09.2022__________ №_137-од________

г. Казань

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 18 гыйнварындагы 006-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 25 апрелендәге 232 номерлы Указы чыгуга бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 18 гыйнварындагы 006-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмәнең 3.4.2. пунктына (Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2018 елның 29 мартындагы 38-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«мәнфәгатьле оешмаларга соратулар җибәрелә ала» сүзләреннән соң «, «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы, шул исәптән соратулар җибәрү өчен кулланылырга мөмкин» сүзләрен өстәргә.

2. Хокук һәм кадрлар эше бүлегенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен уздыруны тәэмин итәргә.

3. Архив тармагын мәгълүматлаштыру секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты рәсми сайтына әлеге боерыкны теркәгән көннән алып бер эш көне эчендә урнаштырырга.

Рәис Г.З. Габдрахманова